| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 май № 305

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче,  2015 ел, 12 март, 146 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлык Тиешле елга торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына субвенцияләр бирү турында шартнамә (алга таба – Шартнамә төзегәннән соң 7 эш көне эчендә әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында билгеләнгән субсидия алучы гражданнарның чираты тәртибендә, Шартнамәдә каралган финанслау күләмнәре кысаларында әлеге Нигезләмәгә 1 нче

кушымтада китерелгән форма буенча субсидия бүлеп бирелгән гражданнарның исемлекләрен (алга таба – исемлекләр) төзи һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына җибәрә.»;

11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тапшырылган Шартнамәдә сатып алына торган торак мәйданы өчен түләү әлеге карар нигезендә бүлеп бирелгән торак сатып алуга субсидияне исәпкә алып башкарылу турында пункт булырга тиеш.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык территориаль социаль яклау органыннан гражданнар тапшырган шартнамәләр турында мәгълүматны алган көннән соң 35 эш көне эчендә тиешле акчаның вәкаләтле банкның тиешле бүлекләре счетларына керүен тәэмин итә, электрон мәгълүмат йөртү җайланмасында (TXT форматта) һәр бүлек буенча субсидия алучылар реестрын терки. Реестрда түләү йөкләмәсенең саны һәм датасы күрсәтелергә һәм субсидия алучының фамилиясе, исеме, әтисе исеме, аның паспорт мәгълүматлары, теркәлү урыны, субсидия алучыга тиешле сумма, агымдагы счеты (банкныкы) саны булырга тиеш.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

200_ ел торышына субсидия бүлеп бирелгән гражданнар исемлеге

_______________________________________________________________ буенча
(Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) исеме)

| Фамилиясе | Исеме | Әтисе исеме | Җенесе | Торак белән тәэмин итү хокукы бирә торган категория | Туу датасы | Исәпкә кую датасы | Теркәлү адресы | Субсидия күләме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

_______________________________________________
(исемлекне төзегән затның Ф.И.Ә.и., вазыйфасы, имзасы)»;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

______________________________________________
Субсидия алучының И.Ф.Ә.и.

______________________________________________
яшәү урыны адресы

______________________________________________
паспорт мәгълүматлары

Торак сатып алуга субсидия бирелү турында хәбәрнамә

Сез торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак федераль бюджет акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга субсидия алуга хокуклы.

Әлеге хәбәрнамәне алган көннән соң бер ай эчендә Сезгә аерым блоклаштырылган максатчан финанс счеты ачу өчен түбәндәге адрес буенча банк бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк:

____________________________________________________________________________,
(банкның исеме һәм адресы күрсәтелә)
аңарга күрсәтелгән субсидия күчереләчәк.

Торак алуга субсидия сыйфатында бүлеп бирелә торган акча хисабына торак сатып алу максатларында Сез территориаль социаль яклау органына ветераннар, инвалидлар, инвалид балалар (субсидия алучы) арасыннан затны гомуми мәйданы 18 кв.метрдан ким булмаган торак белән тәэмин итә торган торак урынны сату-алу шартнамәсен яисә күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган органда теркәлгән бүтән шартнамә тапшырырга тиеш, шуннан соң Сез вәкаләтле банкта ачкан счетка территориаль социаль яклау органыннан гражданнар тапшырган шартнамәләр турында мәгълүмат алынган көннән соң 35 эш көне эчендә субсидия күләмендә финанс чаралары күчерелә, алар киләчәктә Сез сатып ала торган торак урынны сатучыга турыдан-туры күчереләчәк.

Кечерәк мәйданлы торак урын сатып алу рөхсәт ителә, әгәр алыш-биреш нәтиҗәсендә Сез гомуми мәйданнары 18 кв.метрдан ким булмаган торак урыннар милекчесе булсагыз.

Сатып алына торган торак мәйданы өчен түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары нигезендә бүлеп бирелгән торак алуга субсидияне исәпкә алып башкарылуы турында пунктны шартнамәгә кертү кирәклегенә игътибарыгызны җәлеп итәбез.

Әгәр Сез субсидия алудан баш тартасыз яисә хәбәрнамә алган көннән соң өч ай эчендә үзегезнең торак шартларын яхшыртуга хокукыгызны тормышка ашырмаган икәнсез, Сез субсидия алуга дәгъва итүчеләр исемлегеннән төшеп каласыз. Моның белән бергә Сез федераль бюджет акчасы исәбеннән торак шартларын яшыртуга хокукыгызны югалтмыйсыз һәм субсидия алучыларның җыелма исемлегеннән чыгарылмыйсыз. Алга таба Сезнең Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрелгән шәхси гаризагыз буенча Сез кабат субсидия бүлеп бирелгән гражданнар исемлегенә кертеләсез.

Әлеге Хәбәрнамәнең алтынчы абзацында билгеләнгән вакыт Сез Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына торак шартларын яхшыртуга хокукны тормышка ашыру вакытын озайту өчен нигезле сәбәпләрен күрсәтеп язмача гариза биргән очракта озайтылырга мөмкин.

Субсидия күләме ______ сум тәшкил итә.

(Субсидия күләме бер субсидия алучыга гомуми торак мәйданы нормативының (18 кв.метр яки ветераннарның аерым категорияләре өчен 36 кв.метр) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы субсидия алуга дәгъва итүчеләр исемлеген территориаль социаль яклау органына җибәргән көнне гамәлдә булган Татарстан Республикасы буенча 1 кв.метр гомуми торак мәйданының уртача базар бәясенә тапкырчыгышына итигез).

Субсидия алуга риза, федераль бюджет акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга субсидия алу өчен субсидия бирүшартлары белән Танышмын һәм аларны үтәргә йөкләмә алам.

______________________________________________________________________

(Ф.И.Ә.и., хәбәр ителгән зат имзасы, дата)

Субсидия алудан баш тартам

______________________________________________________________________

(сәбәбен күрсәтергә)

Территориаль социаль яклау
органы җитәкчесе ___________ ______________________.

имза имзаның аңлатмасы

м.у.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков